КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 22 ноябрь г.Казань № 1497

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2025 елга кадәр Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 15 май, 319 нчы; 2014 ел, 10 декабрь, 966 нчы; 2015 ел, 30 октябрь, 821 нче; 2016 ел, 12 апрель, 215 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 674 нче; 2017 ел, 13 гыйнвар, 4 нче; 2017 ел, 13 февраль, 80 нче; 2017 ел, 26 июнь, 429 нчы; 2017 ел, 4 октябрь, 760 нчы; 2018 ел, 30 июль, 612 нче; 2018 ел, 2 август, 625 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1194 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1197 нче; 2019 ел, 6 июнь, 472 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1239 нчы; 2020 ел, 8 сентябрь, 809 нчы; 2020 ел, 15 декабрь, 1138 нче; 2021 ел, 25 июнь, 497 нче; 2021 ел, 28 июнь, 513 нче; 2021 ел, 26 июль, 650 нче; 2021 ел, 1 декабрь, 1162 нче; 2021 ел, 22 декабрь, 1263 нче; 2022 ел, 16 май, 451 нче; 2022 ел, 31 май, 506 нчы; 2022 ел, 30 июнь, 615 нче; 2022 ел, 19 июль, 696 нчы; 2022 ел, 31 октябрь, 1155 нче; 2022 ел, 14 декабрь, 1330 нчы; 2022 ел, 16 декабрь, 1353 нче; 2022 ел, 27 декабрь, 1428 нче; 2023 ел, 22 март, 326 нчы; 2023 ел, 23 март, 327 нче; 2023 ел, 30 июнь, 769 нчы; 2023 ел, 31 июль, 914 нче; 2023 ел, 23 сентябрь, 1182 нче; 2023 ел, 5 октябрь,1236 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына

түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

14 нче ярдәмче программада. «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләү» (алга таба – 14 нче ярдәмче программа):

14 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге «Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирламасы» бүлекчәсенең өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2021 – 2025 елларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү тәртибендә каралган беренчел медицина-санитария ярдәмен күрсәтү өчен медицина эшләнмәләрен 13 751 берәмлек күләмендә алмаштыру һәм җиһазлап бетерү планлаштырылган, шул исәптән: 12 013 берәмлек медицина эшләнмәләре һәм таушалу белән бәйле 1 738 медицина эшләнмәсен яңадан җиһазлау.

2021 елдан 2025 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына алдагы җиһазларны демонтажлау эшләре башкарылачак, монтажлана торган медицина җиһазларын урнаштыру өчен бүлмәләрне 131 берәмлек күләмендә яңадан җиһазландыру һәм әзерләү белән: магнит-резонанс томографы - 1 берәмлек, рентген компьютер томографы - 20 берәмлек, стационар рентген аппараты - 41 берәмлек, маммограф - 40 берәмлек, флюорограф - 29 берәмлек.»;

14 нче ярдәмче программаның V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Ярдәмче программаны тормышка ашырудан
көтелә торган соңгы нәтиҗәләр

Ярдәмче программаны тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

авария хәлендәге, җимерүне, реконструкцияләүне һәм капиталь ремонтлауны таләп итә торган халәттәге беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмалары өлешен киметергә 16,6 процентка кадәр киметергә;

елына 1 авыл кешесенә медицина оешмаларында булу санын 5,47 берәмлеккә кадәр арттырырга;

амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләрдә 10 елдан артык файдаланыла торган җиһаз өлешен әлеге төр җиһазларның гомуми санынннан 10,5 процентка кадәр киметергә;

халыкның медицина ярдәменнән канәгатьлелеге буенча җәмәгатьчелек фикерен бәяләүне 64 процентка кадәр арттырырга.

Ярдәмче программаны үтәү Татарстан Республикасы халкына беренчел медицина-санитария ярдәмен үстерү буенча үз илебезнең сәламәтлек саклау системасының стратегик юнәлешен гамәлгә ашыруга импульс булачак.»;

14 нче ярдәмче программаның «Ярдәмче программа максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм аның чаралары буенча финанслау» таблицасының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «3. Инвалидларның һәм сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән халыкның башка төркемнәренең махсус ихтыяҗларын исәпкә алып, беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмаларын, шулай ук үзәк район һәм район хастаханәләрен медицина ярдәме күрсәтү җиһазы белән тәэмин итү | 3.1. Медицина оешмалары паспортларын исәпкә алып, өлкәннәргә һәм балаларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтелә торган медицина оешмаларының, аларның аерымланган структур бүлекчәләренең, үзәк район һәм район хастаханәләренең матди-техник базасын медицина ярдәме күрсәтү тәртибе таләпләренә туры китерү, аларны медицина ярдәмен күрсәтү җиһазы белән җиһазлап бетерү һәм яңадан җиһазлау | ТР ССМ | 2021 – 2025 еллар | Беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында 10 елдан артык файдаланган медицина ярдәме күрсәтү җиһазы санын киметү, берәмлек | 578 | 565 | - | - | - | - | РФ бюджеты | 178 697,7 | 925 879,9 | 694 123,72 | 513 178,7 | 499 854,6 |
| | | | | | | | | | | | ТР бюджеты | 44 722,3 | 231 739,8 | 173 700,93 | 128 340,3 | 125 002,6»; |
| | | | | Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләрдә файдалану срогы 10 елдан артык булган җиһазларның әлеге төр җиһазларның гомуми саныннан өлеше, процент | 0 | 0 | 20,7 | 13,7 | 11,6 | 10,5 | | | | | | |

14 нче ярдәмче программага 8 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

Программага 2 нче кушымтаның «14 нче ярдәмче программа. «Татарстан Республикасы сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләү» бүлегендәге 14.28 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «14.28. | Амбулатория шартларында медицина ярдәме күрсәтүче бүлекчәләрдә файдалану срогы 10 елдан артык булган җиһазларның әлеге төр җиһазларның гомуми саныннан өлеше, процент | процент | - | - | - | - | 20,7 | 13,7 | 11,6 | 10,5». |

2. Бу карар 2023 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин